ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ЫНДЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

6 октябрь, 2023 ел №82

Югары Ындырчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 480-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлеге Советы карар итте :

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлеге Советының «Югары Ындырчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында " 2016 елның 15 апрелендәге 28 номерлы карары белән расланган Югары Ындырчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5.1 пунктында «электрон документ рәвешендә» сүзләреннән соң «, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып» сүзләрен өстәргә (алга таба - Бердәм портал),»;

3.3 пунктның беренче абзацында «язма мөрәҗәгатьтә» сүзен «язма формадагы мөрәҗәгатьтә» сүзләре белән алыштырырга;

3.3 пунктның җиденче абзацында «язма мөрәҗәгатьтә» сүзен «язма формадагы мөрәҗәгатьтә» сүзләре белән алыштырырга;

3.4 пунктның беренче абзацында «язма мөрәҗәгать» сүзен «язма формадагы мөрәҗәгать» сүзенә алыштырырга;

3.7 пунктта «электрон почта адресын» сүзләрен «шулай ук электрон почта адресын күрсәтә яки Бердәм порталда шәхси кабинетның адресын (уникаль идентификаторын) файдалана, «аңа» сүзен «кем» сүзенә алмаштырырга;

4.15 пунктта «вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә,» сүзләреннән соң «яисә гражданның Бердәм порталдагы шәхси кабинетының адресы (уникаль идентификаторы) буенча» сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Югары Ындырчы авыл җирлеге башлыгы –
Югары Ындырчы авыл җирлеге Советы Рәисе Ф.М.Гафиятуллин